ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 30 июне** **Чистай шәһәре** **№ 434**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 93 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 2377-р номерлы, 2021 елның 20 гыйнварындагы 68-р номерлы, 2022 елның 29 апрелендәге 877-р номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 93 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 «2022 елга җирле бюджет акчаларын финанслау (мең сум)» 3 нче кушымтасының 1 пунктында «26,00» санын «26,02» санына алмаштырырга.
1.2 «2022 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау» 2 нче кушымтасына 6 пункт өстәргә.
1.3 «2022 елга җирле бюджет акчаларыннан финанслау» 3 нче кушымтасына 2 пункт өстәргә.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 30 июнендәге
434 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | ел дәвамында | 595,72 |
| 2 | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә түләүләр | ел дәвамында | 20,00 |
| 3 | Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчыларга-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен түләүләр | ел дәвамында | 1800,00 |
| 4 | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында, хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 273,20 |
| 5 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татнефть Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә | ел дәвамында | 2 576,40 |
| 6 | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга, әлеге учреждениеләргә муниципаль биремне үтәү өчен кирәк булган физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны ташу буенча аутсорсинг хезмәтләрен алу өлешендә чараларны гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 476,04 |

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 30 июнендәге
434 номерлы карарына
3 нче кушымта

2022 елга җирле бюджет акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татнефть Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә | ел дәвамында | 26,02 |
| 2 | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга, әлеге учреждениеләргә муниципаль биремне үтәү өчен кирәк булган физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны ташу буенча аутсорсинг хезмәтләрен алу өлешендә чараларны гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 4,76 |